КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 октябрь г.Казань № 955

2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 139.1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 23 октябрь, 955 нче карары белән расланды

2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге тәртип 2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, муниципаль берәмлекләр) бирү механизмын билгели.

2. 2020 елда башка бюджетара трансфертлар мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләүне оештыруга бәйле муниципаль берәмлекләрнең чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә эшләми торган көннәрне игълан итү турында» 2020 елның 25 мартындагы 206 номерлы, «Россия Федерациясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2020 елның 2 апрелендәге 239 номерлы, «Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чараларының гамәлен озайту турында» 2020 елның 28 апрелендәге 294 номерлы указларында (алга таба – указлар) билгеләнгән эш көннәре чорында муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) түләү алуны (алга таба – ата-ана түләве) туктату һәм 2020 елның 12 маеннан ата-ана түләвенең үзгәрүе белән бәйле бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга башка бюджетара трансфертлар бирү өчен бюджет акчаларын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына (алга таба – Министрлык) җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә.

4. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

а) Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү исәбенә муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет язмасы) муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу;

б) Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә вәкаләтле органы (алга таба – вәкаләтле орган) арасында башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү төзү;

в) 2020 елның 12 маеннан ата-ана түләве күләмен раслау турында муниципаль берәмлекнең муниципаль хокукый акты булу.

5. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның гомуми күләме (S) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = \sum_{j=1}^{n} S_j ,$$

монда:

$S_j$ – j-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

n – муниципаль берәмлекләр саны.

6. J-муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме (Sj) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_j = Z_j^p - Z_j^{pl},$$

монда:

$Z_j^p$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2009 ел, 2 июль, 546 нчы карары белән расланган Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу буенча методик тәкъдимнәр нигезендә 2020 елның 1 гыйнварына исәпләнгән 2020 елга j-муниципаль берәмлеккә кергән ата-аналар түләвенең фаразланган күләме»;

$Z_j^{pl}$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2009 ел, 2 июль, 546 нчы карары белән расланган Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу буенча методик тәкъдимнәр нигезендә исәпләнгән, указларда билгеләнгән эш көннәре чорына алынуын туктатып торуны һәм 2020 елның 12 маеннан ата-ана түләве күләмен үзгәртүне исәпкә алып, 2020 елга j-муниципаль берәмлеккә кергән ата-аналар түләвенең план күләме.

7. Башка бюджетара трансфертларны бирү Министрлык һәм вәкаләтле орган арасында төзелгән башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү нигезендә, Министрлык тарафыннан расланa торган форма нигезендә гамәлгә ашырыла (алга таба – килешү).

8. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансферт күләме, аның максатчан билгеләнеше;

башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең мәгънәсе;

башка бюджетара трансфертны күчерү тәртибе һәм сроклары;

финанс белән тәэмин итү чыганагы бүтән бюджетара трансферт булган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнары турында хисап бирү сроклары, тәртибе һәм рәвешләре һәм башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турында хисап бирү сроклары;

вәкаләтле орган тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәүне тикшереп тору тәртибе;

әлеге Тәртиптә билгеләнгән шартлар бозылган очракта килешүне өзү тәртибе;

килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

9. Башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелеген бәяләү башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелек күрсәткече нигезендә гамәлгә ашырыла.

10. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткече булып 2020 елда j-муниципаль берәмлегендә балаларны карау һәм тәрбияләү буенча хезмәтләр күрсәтүгә мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларының чыгымнарын финанс ягыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2009 ел, 2 июль, 546 нчы карары белән расланган Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу буенча методик тәкъдимнәр нигезендә исәпләнгән күләмдә тәэмин итү тора.

11. Министрлык, килешү төзелгәннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 20 көн эчендә муниципаль берәмлек бюджеты акчалары белән операцияләрне исәпкә алу өчен Федераль казначылыкның территориаль органына Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә ачылган шәхси исәп-хисап счетына бүтән бюджетара трансферт күчерә.

12. Вәкаләтле орган 2021 елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Министрлыкка финанс белән тәэмин итү чыганагы башка бюджетара трансферт булган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнары турында хисап һәм килешүдә каралган форма һәм тәртип буенча башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турында хисап тапшыра.

13. Әгәр муниципаль берәмлек 2020 елның 31 декабренә килешүдә каралган башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешмәгән булса, муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына 2021 елның 1 мартына кадәр кире кайтарылырга тиешле акчалар күләме ($V_{возврата}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{возврата} = P \times D\,,$$

монда:

P – 2020 елда муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансферт күләме;

D – башка бюджетара трансфертны кире кайтару коэффициенты.

14. Муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акчалар күләмен 2020 елда муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансферт күләмендә исәпләгәндә 2021 елның 1 гыйнварына кулланылмаган башка бюджетара трансфертның калдыгы күләме исәпкә алынмый.

15. Башка бюджетара трансфертны кире кайтару коэффициенты (D) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең 2021 елның 1 гыйнварына фактта ирешелгән күрсәткече;

S – килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең плandагы әһәмияте.

16. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертны максатсыз файдаланган һәм (яисә) бирү шартларын бозган очракта, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына акчаларны кире кайтармаган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүриләү чаралары кулланыла.

17. 2021 елның 1 гыйнварына кулланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2021 елның беренче 15 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыгы Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, күрсәтелгән акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Министрлык билгеләгән тәртиптә, Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә алынырга тиеш.

Министрлыкның 2020 елда файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карар нигезендә, күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларның калдыкларыннан артмаган күләмдә акчалар 2021 елда алар элегрәк күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен бирелгән муниципаль берәмлек бюджеты керемәнә кире кайтарылырга мөмкин.

18. Вәкаләтле орган тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансферттан максатсыз файдаланган өчен законнар нигезендә җавап тота.

19. Министрлык әлеге Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыра.

20. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту Министрлык тарафыннан башкарыла.